ГЛАВА ЗАИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

30.07.2024 г. Заинск № 343

**Зәй муниципаль районы Советының 2023 елның 30 ноябрендәге 300 номерлы «2024 елга һәм 2025 һәм 2026 еллар план чорына Зәй муниципаль районы бюджеты турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Уставы, Зәй муниципаль районы Советы нигезендә

## КАРАР ИТТЕ:

1. Зәй муниципаль районы Советының 2023 елның 30 ноябрендәге 300 номерлы «2024 елга һәм 2025 һәм 2026 еллар план чорына Зәй муниципаль районы бюджеты турында» карарына (үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән 13.06.2024 № 332) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 статьяның 1 пунктында:

а) 1 өлештә «2063636,8» саннарын «2177366,5» саннарына алмаштырырга;

б) 2 өлештә «2135039,0" саннарын «2248768,7» саннарына алмаштырырга.

1.2. «2024 елга Зәй муниципаль районы бюджеты кытлыгын финанслау чыганаклары» 1 нче кушымтаның 1 нче таблицасына үзгәрешләр кертергә һәм әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә редакциягә бәян итәргә;

1.3. «2024 елга Зәй муниципаль районы бюджеты керемнәренең фаразлана торган күләмнәре» 2 нче кушымтаның 1 нче таблицасына үзгәрешләр кертергә һәм әлеге карарга 2 нче кушымта нигезендә редакциядә бәян итәргә;

1.4. «2024 елга Зәй муниципаль районы бюджеты чыгымнарының ведомство структурасы» 3 нче кушымтаның 1 нче таблицасына үзгәрешләр кертергә һәм әлеге карарга 3 нче кушымта нигезендә редакциядә бәян итәргә;

1.5. «2024 елга Зәй муниципаль районы бюджетының бюджет ассигнованиеләрен бюджет чыгымнары классификациясенең бүлекләре,

бүлекчәләре, максатчан статьялары, чыгымнар төрләре төркемнәре буенча бүлү» 4 нче кушымтасының 1 нче таблицасына үзгәрешләр кертергә һәм әлеге карарга 4 нче кушымта нигезендә редакциягә бәян итәргә;

1.6. «2024 елда Татарстан Республикасы бюджетыннан алына торган бюджетара трансфертлар» 7 нче кушымтаның 1 нче таблицасына үзгәрешләр кертергә һәм әлеге карарга 5 нче кушымта нигезендә редакциядә бәян итәргә;

1.7. «2024 елга җирлекләр бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бүлү» 10 нчы кушымта өстәргә (Татарстан Республикасы резерв фонды һәм Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының Резерв фонды акчалары исәбеннән Татарстан Республикасы бюджетыннан керә торган бюджетара трансфертлардан тыш) һәм әлеге карарга 6 нчы кушымта нигезендә редакциядә бәян итәргә.

2. Зәй муниципаль районы Советының оештыру бүлегенә әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземә йөклим.

**Совет Рәисе** **Р.Г.Кәримов**